Фирүзә Җамалетдинова

# Тешле карандаш



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Җ17

Рәссамы *Алсу Тимергалина*

**Җамалетдинова, Ф. И.**

Җ17 Тешле карандаш : балалар өчен шигырьләр / Фирүзә Җамалетдинова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2018. – 63 б.
ISBN 978-5-298-03620-7

Шагыйрә, язучы Фирүзә Җамалетдинова балалар өчен менә дигән китап әзерләде. Аның әсәрләре, тирән эчтәлекле, кызыклы вакыйгаларга бай. Үрдәк белән чебинең нәрсә турында сөйләшкәнен, бер баланың усал этәч белән ничек дуслашуын, телефонның нинди сурәтләр төшерергә яратуын беләсегез килсә, әлеге җыентыкны укыгыз!

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03620-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2018
© Җамалетдинова Ф. И., 2018

# ЭЧТӘЛЕК

Күбәләк . . . 3
Җиңдем . . . 3
Каникулга чыктык бит . . . 4
Фотограф телефон . . . 4
Үскән туп . . . 5
Керфекле балык . . . 5
Койрыклы бәрәңгеләр . . . 6
Бәрәңгеләр яз көткән . . . 6
Кем өйрәткән? . . . 7
Күгәрченнәр өе . . . 8
Суык . . . 8
Кайсыбыз зуррак? . . . 9
Таган . . . 10
Тимәсеннәр куянга! . . . 11
Үрдәк белән Чеби турында әкият . . . 12
Юл буенда чәчәкләр . . . 13
Пычкы . . . 14
Идән юдым . . . 14
Машина төзәтәләр . . . 15
Куян күчтәнәче . . . 16
Сәхнә . . . 17
Хикмәтле рәхмәт . . . 18
Кояш . . . 19
Судан кайтам . . . 20
Алдакчы күзлек . . . 21
Сүз көче . . . 21
Кызык итте . . . 22
Җитми безнең атларга! . . . 23
Дус . . . 24
Әти патша булган . . . 25
Кәнфит . . . 25
Ашыгырга кирәк шул . . . 26
Тешле карандаш . . . 27

Әти куйган кибән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Абыем төн сагында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Кар ява . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Шуңа якты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Тау булды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Буран йөрде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Уен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Кошлар ничек уйлый икән? . . . . . . . . . . . . . 35
Алдашу һәм алдату . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Оя куйдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Тәгәри көннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Кошчыгым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Кояш микән әллә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Сәлам юлладым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Ничек өйрәтим икән? . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Төлке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Хәйлә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Җир тетрәгәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Үз әнкәсе булса . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Җил сулышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Кояш керде күземә . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Давыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Янартау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Талчыбык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Кыш бабайга һәйкәл . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Кар бабай белән Илшат турында әкият . . . . . . . 55
Кошларны озаттым . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Булышчы җил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Җиләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Безнең чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Каеннарның дәү әнисе . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Карлыгач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Мәңгелек ут . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

## КҮБӘЛӘК

Күлмәгемә кунды ул,
Ерактан килде микән?
Әллә мине күбәләк
Чәчкә дип белде микән?

Онытты күк ул хәтта
Каядыр барасын да.
Торабыз икәүләшеп
Чәчәкләр арасында.

## ҖИҢДЕМ

Алдый-йолдый компьютер,
Түгел һич укытмакчы.
Көне буе үзенә
Каратып утыртмакчы.

Матур җәйнең иртәсе,
Ничек чыгып китәсе?
Компьютерны бүген үк
Ничек кызык итәсе?

Зур уенга кертмәкче,
Белми: мин бит кечерәк.
Урамга чыгып чаптым,
Йә, кайсыбыз көчлерәк?



## КАНИКУЛГА ЧЫКТЫК БИТ

Энә-җеп тоткан әни:
– Тегәсем бар әллә ни...
Чалбарың бит ертык, – ди, –
Шуксың, балам, артык, – ди.

– Әни, ашыкма, әйдә,
Көннәр к-ү-ү-п әле җәйдә.

Каникулга чыктык бит,
Тормыйбыз хәзер иртә,
Күлмәгем дә ял итә,
Чалбарым да ял итә.

Җәйгә шорты да җитә.

## ФОТОГРАФ ТЕЛЕФОН

Җәйнең матурлыгына
Телефон да күз ата.
Ә аннары һәммәсен
Хәтеремдә яңарта.

Бер уйда без, бер сүздә
Табигатькә карата.
Телефон да минем күк
Матурлыкны ярата.

## ҮСКӘН ТУП

Сак кына өргәч эти,
Сулышы бик килешкән.
Бармак чаклы куыктан
Туп кадәрле туп үскән.

Өрелгән дә ул тулган,
Кочакка сыймас булган.
Шулай дәү үскән төштән
Тәгәрәп җиргә төшкән.

Бергә уйныйк, килегез,
Туп ул хәзер, белегез,
Шартлатмасын берегез!

## КЕРФЕКЛЕ БАЛЫК

Әни, күрче, балыкның
Керпесе бар сыртында!
Чү! Чәнечте бармакны,
Алырга бирми тын да.

Әни, күрче, балыкны
Ашап куйдым бит әле.
Калды керфеге генә.
Тәмле булды, бик тәмле!

Керпеле дә, керфекле,
Мин ашаган ак балык.
– Кылчыклы! – диде әни,
Һәммәсен чүпкә салып.